**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлегенең Мостафин авылы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**11.11.2020 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Мостафин авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Мостафин авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк затлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 250 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

-Мостафин авылында урамнарны яктырту лампаларын ремонтлау, сатып алу һәм алыштыру;

-Беларус тракторын карап тоту-82,1 (машина йөртүче эше өчен түләү, запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары);

-Мостафин авылында чишмәне торгызу һәм аның территориясен төзекләндерү өчен материаллар сатып алу;

-Мостафин авылы Октябрь урамына вак таш сатып алу.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Петровский Завод авыл җирлегенең Мостафин авылы стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматнын рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән сон 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге башлыгы А. Б. Хөснетдинов